ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

«20) сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналар территорияләрендә төзелгән индустриаль (сәнәгать) паркларның Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән идарәче компанияләре – индустриаль (сәнәгать) парк эшчәнлеге максатларында булдырылган һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан файдалануга тапшырылган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Салым исәпләнгән салым суммасының 50 проценты күләмендә түбәндәгеләр тарафыннан түләнә:

1) сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре – махсус икътисадый зоналар төзү турындагы килешүләрне гамәлгә ашыру максатларында булдырылган һәм идарәче компания балансында төп чаралар

объекты буларак санала торган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә куйган айдан соң килә торган айдан башлап ун ел узгач, мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән;

2) сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналар территорияләрендә төзелгән индустриаль (сәнәгать) паркларның Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән идарәче компанияләре – индустриаль (сәнәгать) парк эшчәнлеге максатларында булдырылган һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан файдалануга тапшырылган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән.»;

2) 5 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2026 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 20 пунктын, $1^1$ өлешен, $3^1$ өлешенең 1 пунктын;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) 2029 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы $3^1$ өлешенең 2 пунктын.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасындагы дүртенче абзацыннан тыш, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасындагы дүртенче абзацы 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 01 декабрь
№ 86-ТРЗ